**Гумеров И.Г. Касыйм Бикколов иҗаты / Актуальные проблемы естественных и гуманитарных наук. В 2-х частях. Часть II. Материалы международной научно-практической конференции. - Казань: Изд-во "ТАИ". - С. 45-48.**

**Бу мәкаләдә XX гасыр башы әдәбиятының бер вәкиле – Касыйм Бикколов иҗаты барлана. Аерым алганда аның "Нәмүнәи тәрәккый" (*"Прогресс үрнәкләре"*) җыентыгына (Казан, 1904) кергән шигырьләре һәм "Төркестан" (Казан, 1908) исемле тарихи прозаик әсәре анализлана. Әлеге әсәрләренең идея-эстетик үзенчәлекләре, сәнгати эшләнелеш дәрәҗәсе хакында сүз алып барыла. Әдипнең татар әдәбияты үсешенә керткән өлеше, XX гасыр башы сүз сәнгате тарихында тоткан урыны турында сөйләнелә.**